ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
**ЗАКОНЫ**

# «Салым түләүчеләрнең аерым категорияләре өчен оешмалар табышына салым буенча салым ставкасын билгеләү турында» Татарстан Республикасы Законының 2 статьясына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2019 елның 14 февралендә
кабул ителде

**1 статья**

«Салым түләүчеләрнең аерым категорияләре өчен оешмалар табышына салым буенча салым ставкасын билгеләү турында» 2008 елның 2 августындагы 53-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 2 статьясына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2008, № 8 (I өлеш); 2009, № 6; 2011, № 5, № 11 (I өлеш); 2012, № 11 (I өлеш); 2013, № 10) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 1 өлештә «2026 елның 1 гыйнварыннан үз көчен югалта һәм» сүзләрен төшереп калдырырга;

2) түбәндәге эчтәлекле 3 өлеш өстәргә:
«3. Оешмалар табышына салым буенча әлеге Законның 1 статьясында билгеләнгән киметелгән салым ставкалары салым түләүчеләр тарафыннан әлеге салым ставкаларының гамәлдә булу срогы тәмамланганчы кулланылырга тиеш, әмма 2023 елның 1 гыйнварыннан да соңрак түгел.».

**2 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән соң бер ай узгач, әмма оешмалар табышына салым буенча чираттагы салым чорының беренче числосыннан иртәрәк булмаган вакытта үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Президенты Р.Н. Миңнеханов

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ АППАРАТЫ
ГОМУМИ БҮЛЕК
ОБЩИЙ ОТДЕЛ
АППАРАТ ПРЕЗИДЕНТА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

Казан, Кремль
2019 ел, 01 март
№ 17-ТРЗ